ГЛАВА БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БИЛӘР АВЫЛ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.10. 2021 с. Билярск № 6

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегенең Биләр авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәсендәге 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктлары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 октябрендәге 109 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. 2021 елның 10 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегенең Биләр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Биләр АМЙ бинасында билгеләп куярга.

2. 2021 елның 10 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегенең Биләр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Биләр АМЙ бинасында билгеләргә.

3. Биләр елгасының сул як ярында яшәүче гражданнар җыенының беренче этабында катнашу өчен билгеләргә.

Биләр елгасының уң як ярында яшәүче гражданнар җыенының икенче этабында катнашу өчен билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Биләр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны тоту (юлларны кардан чистарту, юл читендәге үләннәрне чаптыру);
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү (Комсомол ур., Украина ур., Совет ур., Киң ур.);
- җирләү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (авария хәлендәге агачларны кисү һәм җыештыру, шартнамә буенча түләү);
- техниканы - тракторны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);
- торак пунктларда урамнарны яктырту;
- суүткәргечне ремонтлау;
- эре габаритлы чүп-чар җыю (айга бер тапкыр)

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Биләр ав., Калинин ур., 3 й.; Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Биләр ав., Ленин ур., 6 й.; Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Биләр авыл җирлеге башлыгы** **Г.Г.Хәбибуллин**